**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Нижнебишевского**
**сельского поселения Заинского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Түбән Биш авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

Ул. Центральная, д. 46, с. Нижнее Бишево, Заинский район, 423514

Центральная урамы, 46 нче йорт, Түбән Биш авылы, Зәй районы, 423514

Телефон, факс 68-4-47. Электронный адрес: Nbsh.Zai@tatar.ru, сайт: www.nigneebishevo.ucoz.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«29» декабрь 2022 ел** **№ 19**

**"Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында" 2020 елның 13 апрелендәге 6 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында" 2020 елның 13 апрелендәге 6 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12 пунктның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 15.1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Д.В.Насертдинов**